# ХАЛЫК ҖЫЕНЫ КАРАРЫ

Татарстан Республикасы Алексеевск муниципаль районы Зур Тигәнәле авыл җирлеге составына керүче Әшнәк авылы

17 декабрь 2021 ел № 2

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» Федераль законның 25.1, 56 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы нигезендә, Татарстан Республикасы Алексеевск муниципаль районының Зур Тигәнәле авыл җирлеге составына керүче Әшнәк торак пунктында гражданнар җыены

**карар итте**:

1.2022 елда Зур Тигәнәле авыл җирлеге территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган кешегә, 1 нче төркем инвалидлардан, көндезге бүлектә укучы студентлардан, Россия Армиясе сафларына чакырылган гражданнардан тыш, 500 сум күләмендә үзара салым кертергә, алынган акчаларны түбәндәге чараларга юнәлдерергә:

- җирлек эчендәге юлларны карап тоту (ягулык-майлау материалларын сатып алу, шартнамә буенча эшләр һәм хезмәт күрсәтүләр өчен түләү);
- җирлек эчендәге юлларны ремонтлау һәм төзү (сатып алу, күчереп йөртү, вак таш салу, шартнамә буенча эшләр өчен түләү);
- Әшнәк авылында урамнарны яктыртуны карап тоту (урам фонарьларын, исәпкә алу приборларын, таймерларны, СИП чыбыкларын сатып алу, шартнамә буенча хезмәт өчен түләү);
- җәйге чорда (ягулык-майлау материаллары сатып алу, шартнамә буенча эшләр һәм хезмәт күрсәтүләр өчен түләү) территорияне каралту һәм үләнне чабу;
- каты көнкүреш калдыклары җыю өчен контейнер мәйданчыклары урнаштыру һәм контейнерлар сатып алу (төзелеш материалы сатып алу, эшләр һәм хезмәт күрсәтүләр өчен түләү шартнамә буенча);
- су манарасы өчен насослар сатып алу;
- тракторны карап тоту һәм ремонтлау (ягулык-майлау материаллары, запас частьләр сатып алу, эшләр һәм хезмәт күрсәтүләр өчен шартнамә буенча түләү).

2. Әлеге карарны Зур Тигәнәле авыл җирлегенең рәсми сайтында, хокукый мәгълүмат порталында, шулай ук Татарстан Республикасы Алексеевск муниципаль районы Зур Тигәнәле авыл җирлеге Советы бинасында мәгълүмат стендында урнаштырырга.

3.Әлеге карарны Татарстан Республикасы муниципаль норматив хокукый актлары Регистрына кертү өчен җибәрергә.

**Гражданнар җыенында рәислек итүче,**
**Алексеевск муниципаль районы**
**Зур Тигәнәле авыл җирлеге башлыгы** **Н.Ө.Хәмитшин**